**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 18 июнь № 414

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәт күрсәтүләрнең индивидуаль программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 ноябрь, 908 нче карары белән расланган Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәт күрсәтүләрнең индивидуаль программасын төзү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәт күрсәтүләрнең индивидуаль программасын төзү эшен камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәт күрсәтүләрнең индивидуаль программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 ноябрь, 908 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 13 март, 151 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәт күрсәтүләрнең индивидуаль программасын төзү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 пункттагы таблицаның 3 графасында:

1 пунктның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең шәхси программасы яки инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең шәхси программасы;»;

2 пунктның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең шәхси программасы яки инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең шәхси программасы;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков